| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Терсинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Тирсә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2024 Тирсә авылы № 48-2

«Тирсә» территориаль иҗтимагый
үзидарә территориясе чикләрен
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Әгерҗе муниципаль берәмлегенең «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында нигезләмә, Тирсә авыл җирлегенең 13.11.2023 елның 40-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территориянең чикләрен билгеләү турында инициатив төркемнең тәкъдимен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Тирсә, Мордывый, Тоба, Нәҗәр һәм Чишмә авыллары гражданнары яшәгән территорияләр чикләрендә "Тирсә" территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары А.Н. Латыйпов